Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«26» февраль 2020 ел № 146

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” Советының 2017 ел 22 августындагы 61 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Совет депутаты статусы турында Нигезләмә” гә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 61 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының гомуми җыелышында (конференция), түләүсез нигездә катнашу, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан белдерү кәгазе белән катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советында, Муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер) булган оешманы гамәлгә куючы мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган, хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

5) гражданлык, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу эше буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнашырга.»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 нчы йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9 нчы йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе А.Г. Җиһаншин